| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» сентябрь 2019 с. Тюлячи № 518

2019-2020 елларның көзге-кышкы янгын куркынычы чорында икътисад тармагы объектларының һәм торак пунктларының янгын куркынычсызлыгын көчәйтү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә һәм янгыннар белән хәлне тотрыклыландыру, кешеләр үлеменә юл куймау, район объектларын һәм торак пунктларын 2019-2020 елларның көзге-кышкы янгын куркынычы чорында эксплуатацияләүгә үз вакытында әзерләү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре районара бүлеге башлыгына (Галимуллин А.Р.) һәм «Татарстан Республикасы буенча 7 федераль янгын куркынычсызлыгы хезмәте» ФДКУ 134-янгын бүлеге башлыгына (Шәрипов М.М.) тәкъдим итәргә:

- янгыннар нәтиҗәсендә килеп туган хәлне анализлауны исәпкә алып һәм РФ гамәлдәге законнары кысаларында авыл җирлекләренә, беренче чиратта, янгынга каршы иң кискен һәм имин булмаган авыл җирлекләренә күзәтчелек чаралары (профилактик тикшерүләр) оештырырга, җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруга аерым игътибар бирергә;

- 2019 елга тикшерүләр графигы нигезендә һәм алдан билгеләнгән срокларда ДЯК башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм техник күзәтчелекнең башка төрләре вәкилләре белән берлектә 01.12.2019 елга кадәр электр энергетикасы, торак-коммуналь хуҗалык һәм җылылык бирү котельныйларын, шулай ук районның торак фондын, беренче чиратта, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә иң имин булмаган торак

җирләрне тикшерүләрне уздырырга, янгын вакытында, федераль законнар тарафыннан ДЯК органнарына бирелгән чараларны тулы күләмдә кабул итеп, янгынга каршы торучанлыгы түбән булган йортларга аерым игътибар бирергә;

- җылылык, электр җиһазлары һәм электр приборлары кулланганда халыкка янгын куркынычсызлыгы чараларын аңлату эшен активлаштырырга. Халыкка янгыннар белән оператив хәл турында, көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларын куллануны буенча мәгълүмат бирүне оештырырга;

- «Торак-2019» күзәтчелек-профилактика операциясен оештыру һәм үткәрү эшен ТР буенча 7 федераль янгын куркынычсызлыгы хезмәте ФДКУнең 134-ЯБ, Олы Нырсы авылы АП ППХ, ирекле янгын сагы әгъзалары, торак оешмалары, социаль оешмалар һәм полиция хезмәткәрләрен җәлеп итеп, торак фондында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау эшен дәвам итәргә;

- яңа ел чыршыларын һәм бәйрәм тантаналарын үткәргәндә янгын-профилактика чаралары комплексын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга;

- район һәм авыл җирлекләре территорияләрен янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларын тикшерүне оештырырга, аларның әйләнә-тирә мохитнең түбән температуралы шартларда эшкә яраклылыгын тәэмин итү һәм янгын сүндерү техникасы белән су алу мөмкинлеге булсын өчен әлеге чыганакларга керү юлларын кардан (боз) чистарту чараларын күрергә;

- район торак пунктларының торак фондын янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне басма массакүләм мәгълүмат чараларында һәм радиоканалларда яктыртуны оештырырга.

2. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- ирекле янгын берләшмәләренең көзге-кышкы янгын чыгу чорына әзерлеген һәм җиһазланышын тикшерергә;

- янгын техникасын һәм җайлаштырылган техниканы төзек хәлгә китерергә;

- кышкы чорда су башняларын су алу өчен җайланмалар белән тәэмин итәргә;

- янгын куркынычы булган чорда эксплуатацияләү өчен шәхси объектларны янгынга каршы торыш халәтенә китерергә;

- кышкы чорга күчү вакытында, терлекчелек биналарын әзерләргә.

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:

- торак пунктларның буаларын, гидрантларын, колонкаларын, сулыкларын тикшерү һәм ремонтлауны оештырырга;

- торак йортларда янгыннарны булдырмау буенча халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалауны оештырырга;

- торак пунктларын һәм торак фондын янгынга каршы саклауны арттыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннарын һәм халык белән очрашулар үткәрүне оештырырга;

- объектларга, су чыганакларына һәм торак пунктларга юлларны вакытында чистартырга;

- хуҗасыз корылмаларда һәм, билгеле бер яшәү урыны булмаган, кешеләр яши ала торган башка урыннарда янгыннарны профилактикалау чараларын тормышка ашыру турындагы мәсьәләне хәл итәргә.

4. Икътисад объектлары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- янгын сүндерү берләшмәләренең һәрвакыт әзер торуын тикшерергә, өйрәнүләр уздырырга;

- объектлар территориясендәге янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын тикшерергә һәм ремонтларга;

- янгын куркынычы янаган чорда эксплуатацияләү өчен шәхси объектларны тиешле хәлгә китерергә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин